КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 октябрь г.Казань № 878

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1462 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1462 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 27 март, 358 нче, 2024 ел, 18 март, 156 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «грантлары» сүзе алдына «Рәисе» сүзен өстәргә;

преамбулада татар текстында «грантлары» сүзе алдына «Рәисе» сүзен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «грантлары» сүзе алдына «Рәисе» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «грантлары» сүзе алдына «Рәисе» сүзен өстәргә;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә нигезендә эшләнде һәм Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү (алга таба шул ук эзлеклелектә – субсидия, сайлап алуда катнашучы, грантлар бирү буенча конкурслар, социаль проект) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү;

гражданлык һәм хокук характерындагы шартнамәләр буенча җәлеп ителә торган затларның хезмәте өчен түләү;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

чит оешмаларның һәм физик затларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләү (юридик һәм бухгалтерлык хезмәтләре, фотога һәм видеога төшерү);

почта һәм курьер чыгымнары;

чыгым материаллары сатып алу;

типография чыгымнары;

банк хезмәте күрсәтү;

транспорт чыгымнары (шул исәптән ягулык-майлау материалларына);

хезмәткәрләрнең командировка чыгымнары;

грантлар бирү буенча конкурсларга тәкъдим ителгән социаль проектларга экспертиза үткәргән өчен хезмәт күрсәтүләргә түләү;

социаль проектларны гамәлгә ашыру мониторингын оештырган өчен хезмәт күрсәтүләргә түләү;

төгәлләнгән социаль проектларның ирешелгән эффектларына бәйсез бәяләүне оештырган өчен хезмәт күрсәтүләргә түләү;

массакүләм мәгълүмат чараларында грантлар бирү буенча конкурслар үткәрү барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту;

мәгълүмати-технологик хезмәт күрсәтүләр (электрон имза алу, бухгалтерлык һәм склад исәбе системасы, болыт саклагычында урын сатып алу, техник яктан тәэмин итү, сервислар арендалау, программалар кую һәм шәхси компьютерларга хезмәт күрсәтү);

элемтә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре хезмәтләре өчен түләү;

2024 елда барлыкка килгән йөкләмәләр буенча күчемсез мөлкәтне (торак булмаган бинаны) карап тотуга һәм аларга хезмәт күрсәтүгә (хезмәт биналарын җыештыру; техник хезмәт күрсәтү: вентиляция, лифт, локаль челтәрләр һәм видеокүзәтү системалары, су белән тәэмин итүнең һәм канализациянең йорт эчендәге системалары, үзәктән җылыту, электр белән тәэмин итү системалары, автоматлаштырылган янгын сигнализациясе системаларына, керүне контрольдә тоту һәм саклау сигнализациясе системасына хезмәт күрсәтү) түләү;

2024 елда барлыкка килгән йөкләмәләр буенча коммуналь хезмәтләр (җылылык, су-, энергия белән тәэмин итү), күчемсез милеккә (торак булмаган бинага) хезмәт күрсәткән өчен түләү;

2024 елда барлыкка килгән йөкләмәләр буенча күчемсез милекне (торак булмаган бинаны) саклау хезмәтләре өчен түләү;

2024 елда барлыкка килгән йөкләмәләр буенча күчемсез милекне (торак булмаган бинаны) иминләштерү хезмәтләре өчен түләү;

җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процenttан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия

Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә түгел;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны кәгазь чыгынакта кулга яки 420021, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55 нче йорт адресы буенча почта аша тапшыра:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы бирә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турындагы башка мәгълүматны

бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлап алуда катнашучының ризалыгы бирелгән, үзенең түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада булган заявка;

чыгымнарның финанс-икътисадый нигезләве, шул исәптән планлаштырыла торган чыгымнар юнәлешләре калькуляциясе бирелгән, аларның күләмнәре нигезләнә торган мәгълүмат, шулай ук алу чыганагы күрсәтелгән субсидия күләменең җентекле исәп-хисабы (счетлар, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең коммерция тәкъдимнәре, җитештерүченең бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат);

сайлап алуда катнашучының штат расписаниесе күчермәсе;

үз эшчәнлеген дәвам итү турында мәгълүматны сайлап алуда катнашучы тарафыннан Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөһер белән таныкланган (мөһер булганда) мәгълүмат тапшыруныраслый торган документның күчермәсе;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе кул куйган гарантияле хат әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган сайлап алу үткәрү планлаштырыла торган айның беренче көненә һәм әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата куелган таләпләргә туры килүе турында;

күчемсез милектән түләүсез файдалану шартнамәсенең күчермәсе;

хезмәтләр күрсәтүгә, эшләр башкаруга шартнамәләрнең һәм эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне раслый торган документларның күчермәләре кушымтасы белән, 2024 елда барлыкка килгән йөкләмәләр буенча хезмәтләр күрсәтүчеләр белән үзара исәп-хисаплар исемлеге актлары,

сайлап алуда катнашучы тарафыннан социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен «Грант конкурсы» АМСннан файдалану хокукын раслый торган документ күчермәсен;

сайлап алуда катнашучы үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы үтәлеше турында белешмә формасын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендщге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын салым түләүче (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәү турында салым органының белешмәсеhttps://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=436518&dst=100016&field=134&date=09.09.2024.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан бу пунктның унберенче һәм уникенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып

ала.»;C:\opt\r7-office\desktopeditors\editors\web-apps\apps\documenteditor\main\index.html - p9

түбәндәге эчтәлекле 4.6 пункт өстәргә:

«4.6. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.»;

5.2 пунктта:

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә;

субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + \ldots + З_n + Z_1 + Z_2 + Z_3,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, …, $З_n$ – бу Тәртипнең 1.6 пунктындагы өченче, бишенче – унынчы, уникенче – егерме икенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар суммасы;

Z1 – штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен хезмәткәрләрнең исәпләнә торган саныннан, исәпләнә торган вазыйфаи окладлардан, түләүләрне стимуллаштыручы вазыйфаи окладка айлык өстәмәләрдән, шулай ук расланган штат расписаниесе нигезендә Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән чыгып билгеләнә торган түләү чыгымнары;

$Z_2$ – салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү чыгымнары;

$F_3$ – Россия Федерациясе законнарында каралган чыгымнарны каплау нормаларыннан чыгып билгеләнә торган хезмәткәрләрнең командировка чыгымнары өчен түләү белән бәйле чыгымнар.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте үсеше турында аналитик мәгълүмат әзерләү – кимендә бер;

грантлар бирү конкурсы үткәреләчәк «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында профилактик эшләр үткәрү – кимендә ике;

массакүләм мәгълүмат чараларында (яки социаль челтәрләрдә) субсидия алучы эшчәнлеге һәм грантлар бирү конкурсларын үткәрү турында кимендә биш мәгълүмат бирү характерындагы хәбәрләр бастырып чыгару;

коммерциягә карамаган оешмалар өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында грантлар бирүгә заявкалар формалаштыру буенча консультацияләр оештыру – кимендә 60 консультация;

экспертлар өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында коммерциягә карамаган оешмаларның грантлар бирү турындагы заявкаларына экспертизалар үткәрү буенча консультацияләр оештыру – кимендә 20 консультация;

граждан җәмгыяте институтларын үстерү чараларын үткәрү - кимендә 5 чара.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

6.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында каралган, субсидияне алучы тарафыннан тапшырылган хисапларны аларны тапшыру датасыннан 20 эш көне эчендә тикшерә.»;

6.3 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин